СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
422060, Республика Татарстан, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 35 25.02.2016

№ ________ от _________________

# КАРАР

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы Уставына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты турында

2014 елның 19 декабрендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставын «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131 номерлы Федераль законга туры китерү максатларында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Россия Федерациясе Федераль законының 44 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы карары, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставы белән Саба муниципаль районы прокуратурасы күрсәтмәсен карап, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектын расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты буенча «Саба муниципаль районында гавами тыңлаулар турында нигезләмә проекты хакында» 2006 елның 21 декабрендәге 94 номерлы карары белән расланган тәртиптә 2016 елның 4 апрелендә 09.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров ур., 52 йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының утырышлар залында гавами тыңлаулар уздырырга.
3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның алар турында фикер алышуда катнашу тәртибен расларга.

4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне 2016 елның 1 апреленә кадәр Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советына җибәрергә.

5. Түбәндәгеләрне бастырып чыгарырга:

– «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында ;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның турында фикер алышуда катнашу тәртибен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектының ачык тыңлауларын уздыру тәртибен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы А.И. Миңнекаевка йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов